**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**КАРАРЫ**

**27 август 2018 ел** **№ 144**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 77нче маддәсе, 2004 елның 28нче июлендәге 45-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 7нче маддәсе, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 99нчы, 100 нче маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. 2005 елның 8нче декабрендәге 19 номерлы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы карары белән кабул ителгән “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына, 1номерлы кушымта нигезендә, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Кушымтаның 2нче пунктның “а” пунктчасының икенче һәм өченче абзацлары 2018 елның 30 декабреннән, кушымтаның 2нче пунктның “а” пунктчасының дүртенче һәм бишенче абзацлары 2019 елның 1нче гыйнварыннан гамәлгә керә.
3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уставына кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне дәүләт теркәве өчен Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе юстиция Министрлыгы Идарәсенә юлларга.
4. Әлеге карарны, дәүләт теркәвеннән соң, “Волжские зори”, “Идел таңнары” газеталарында бастырырга һәм Кама Тамагы муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Башлыгы, Кама Тамагы**
**муниципаль районы**
**Советы рәисе** **П. Н. Лоханов**

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы
муниципаль районы
Советы карарына
1нче номерлы
кушымта
27.08.2018 ел. № 144

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

1. 6нчы маддәнең 1.1 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1.1. гамәлдәге муниципаль берәмлекне үзгәртү юлы белән яңа төзелгән муниципаль берәмлеге булдырылган очракта, җирле үзидарә органнары структурасы җирле референдумда халык белән (муниципаль берәмлектә яши торган сайлау хокукына ия халыкның 300 дән артык булмаган кешесе - халык җыенында) яки муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә һәм муниципаль берәмлекнең уставында ныгытыла.

2. 7нче маддәдә:
а) 1нче өлештә:
5нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“5) район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән ары җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына караган юл эшчәнлеге, торак пунктларның чикләреннән ары Район чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юллары иминлегенең муниципаль контролен гамәлгә ашыру, аларда юл хәрәкәтен оештыру һәм юл хәрәкәтенең куркынычсызлыгын тәэмин итү, шулай ук, Россия Федерациясе законнары нигезендә, автомобиль юлларын файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендәге бүтән вәкаләтләрне тормышка ашыру”.
14нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“14) Район территориясендәге каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю), транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү буенча эшчәнлек оештыруда катнашу”;
25нче пунктны “(волонтерлык буенча”) сүләре белән тулыландырырга;
34нче пунктта “Районның авыллар арасындагы территориясе чикләрендә планировкалау структурасының исемен элементларына” сүзләрен төшереп калдырырга.

3. 7.1 маддәсенең 1нче өлешендә:
ә) 6нчы пунктны үз көчен югалткан дип танырга;
б) 12нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“12) федераль законнар тарафыннан урнаштырылган тәртиптә һәм шартларда, оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтүнең бәйсез бәяләү сыйфаты шартларын уздыруны оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук, ведомство карамагындагы оешма җитәкчеләренең эшчәнлегенә бәя биргәндә, оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартларының сыйфатының бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм, федераль законнар нигезендә, оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтүнең бәйсез бәяләү сыйфаты шартларын уздыру нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар кабул итү артыннан контрольне гамәлгә ашыру;”
в) түбәндәге эчтәлекле 14нче пункт белән тулыландырырга:
“14) физик культураның һәм инвалидлар спортының, мөмкинлекләре чикле кешеләрнең, адаптив физик культураның һәм адаптив спортның үсешенә ярдәм күрсәтү”.
4. 10нчы маддәнең 5нче пунктын “иҗтимагый фикер алышулар” сүзләре белән тулыландырырга”.
5. 15нче маддәдә:
ә) статьяның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“Ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар”;
б) 3нче өлешне түбәндәге эчтәлекле 2.1 пункты белән тулыландырырга:
“2.1) Районның социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты;”;
в) 3нче өлешнең 3нче пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
г) түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлеше белән тулыландырырга:
“3.1. генераль планнар проектлары буенча, җирдән файдалану һәм төзү проектлары буенча, территорияне планлаштыру проектлары, ызанлау проектлары, территорияләрне төзекләндерү проектлары буенча, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күзаллаган проектлар, шартлы рәвештә рөхсәт иткән җир участогын яки капиталь төзелеш объектын куллануны рөхсәт иткән карарлар проектлары буенча, рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү карарлары проектлары буенча, капиталь төзелешнең объектларын реконструкцияләү буенча, җир участокларының һәм капиталь төзелеш объектларының файдалануга рөхсәт ителгән бер төрен шундый куллану төренең икенчесенә үзгәртү мәсьәләләре буенча, җирдән файдалануның һәм төзелешнең расланган кагыйдәләре булмаганда, иҗтимагый фикер алышу яки ачык тыңлаулар үткәрелә, аларның оештыру һәм үткәрү тәртибе муниципаль берәмлекнең уставы һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законның нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә.
6. 29нчы маддәдә:
ә) 1нче өлешнең 5нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“5) Районның социаль-икътисадый үсеше стратегиясен раслау;”;
б) 1нче өлешне түбәндәге эчтәлекле 5.1 пункты белән тулыландырырга:
"5.1) Районның муниципаль идарәсенең һәм социаль-икътисади үсешенең озак вакытлы максатларын һәм бурычларын билгеләү, Районның җирле үзидарә

органнарының вәкаләтләренә караган мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын карау һәм раслау (хуплау);";

7. 49нчы маддәне түбәндәге эчтәлекле 2.1 өлеш белән тулыландырырга:

"2.1. Татарстан Республикасы Президенты гаризасы нигезендә суд тәртибендә, чикләүләр, тыюларны, бурычларны үтәмәү сәбәпле, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы тору турында"гы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның керемнәренә чыгымнары туры килү-килмәү артыннан контроле турында"гы Федераль законы, 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы "Аерым категорияләрдәге затларга счетлар (кертем) ачарга һәм аларга ия булырга, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында кулдагы акчалар һәм кыйммәтләр сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга" Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы законнары нигезендә, тикшерү нәтиҗәсендә керемнәре, чыгымнары турындагы, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы, Федераль закон нигезендә бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында"гы, Башкарма комитет җитәкчесе белән контракт гамәлдән туктатылырга мөмкин".

8. 44нче маддәнең 1нче өлешенең 1нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1) планлаштыру, бюджет, финанслар һәм исәп алу өлкәсендә:

- Район бюджеты проектын, Район социаль-икътисади үсеш стратегиясе проектын әзерли;

- Район бюджеты үтәлешен тәэмин итә, Район социаль-икътисадый үсеше стратегиясен тормышка ашыруны оештыра;

- җирлек бюджет үтәлеше турында хисап, җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру турында хисаплар әзерли;

- Районның икътисад һәм социаль өлкә халәтен характерлаучы статистик күрсәткечләрне җыюны һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, дәүләт хакимияте органнарына күрсәтелгән мәгълүматларны бирүне оештыра;

- Районың җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә караган стратегик планлаштыру мәсьәләләре буенча документларны эшләү һәм тормышка ашыру;

- Район Советы тарафыннан расланган (хупланган) стратегик планлаштыру документларын гамәлгә ашыруның мониторингы һәм контрольдә тоту;".

9. 73нче маддәнең 3нче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Гамәлгә куючысы булып Район торган, оешманың хокукый статусын билгеләүче, кеше һәм гражданинның хокукларына, ирекләренә һәм вазыйфаларына кагылучы муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасындагы килешүләр, аларны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка хәбәр ителгәннән) соң үз көченә керә.".

10. 99нчы маддәнең 3нче өлешенең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Район уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка хәбәр итү), шулай ук, гражданнарның аның буенча

фикер алышуда катнашу тәртибен (Район уставына Россия Федерациясе Конституциясенең нигезләмәләренең, федераль законнарның, Татарстан Республикасы Конституциясенең яки Татарстан Республикасы законнарының, әлеге уставның шушы норматив хокукый актлар белән туры китереп төгәл формада күрсәтелгән үзгәрешләре кертелгән очракта) кирәк түгел.

11. 100нче маддәнең 3нче өлешен түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

“Район башлыгы Район Советы рәисе вәкаләтләрен башкаркан очракта, Район уставын, Район уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт кабул иткәндә, Район башлыгы тавышы Район Советы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.

а) 3нче өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Чын уставка кертелгән һәм җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртүче үзгәрешләр һәм өстәмәләр, җирле үзидарә органнары арасындагы вәкаләтләрне бүлү (Район уставын федераль законнарга туры китерү, шулай ук җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаи затларының вәкаләтләрен, вәкаләтләре вакытын, сайлау тәртибен үзгәртү белән бәйле очраклардан тыш), чын уставка күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый актны имзалаган Район башлыгының вәкаләтләре вакыты гамәлдән чыкканнан соң көченә керә.”.

б) түбәндәге эчтәлекле 4нче өлеш белән тулыландырырга:

“3.1. Чын уставка муниципаль хокукый акт белән түбәндәгечә рәсмиләштерелергә мөмкин булган үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә:

1) Район Советы рәисе һәм Район башлыгы тарафыннан кул куелган, яисә Район Советы рәисе (гражданнар җыены) вәкаләтләрен башкаручы Район башлыгының үзе тарафыннан кул куелган Район Советы (гражданнар җыены) карары белән;

2) Совет (гражданнар җыены) тарафыннан кабул ителгән һәм Район башлыгы тарафыннан кул куелган аерым норматив хокукый акт белән;

Бу очракта аның кабул ителүе турында әлеге хокукый актта Совет (гражданнар җыены) карарларының реквизитлары куела. Күчерелмә нигезләмәләрне һәм (яки) Район уставына кертелә торган үзгәрешләрнең һәм өстәмәләрнең үз көченә керүе турындагы нормаларны мондый Совет карарына кертү рөхсәт ителми.”;

в) түбәндәге эчтәлекле 5нче өлеш белән тулыландырырга:

“5. Район уставын федераль законнарга, Татарстан Республикасы законына туры китерү бу закон актлары белән билгеләнгән вакытта гамәлгә ашырыла. Федераль закон, Татарстан Республикасы законы тарафыннан күрсәтелгән вакыт билгеләнмәгән очракта, район уставын федераль законнарга, Татарстан Республикасы законына туры китерү вакыты тиешле федераль законның, Татарстан Республикасы законының үз көченә керү датасын, Район уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт проектын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм җәмәгать тыңлауларында фикер алышуны, аның буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алуны, Район Советының утырышларының ешлыгын, дәүләт теркәвенә алуның вакытларын һәм мондый муниципаль хокукый актны рәсми бастырып чыгаруны (халыкка җиткерү) исәпкә алып билгеләнә һәм, кагыйдә буларак, алты айдан артмаска тиеш.

г) түбәндәге эчтәлекле 6нчы өлеш белән тулыландырырга:

“6. Муниципаль хокукый акт тарафыннан Район уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында яңа редакциядә бәян итү рөхсәт ителми. Бу очракта яңа Район уставы кабул ителә, ә элек гамәлдә булган Район уставы һәм үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакындагы муниципаль хокукый актлар, яңа Район уставы үз көченә кергән көннән алып, үз көчләрен югалткан дип таныла.